**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»
СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ, 423106

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а
БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ, 423106

тел./факс email: +7(84396) 2-64-66;
Berk.Cmn@tatar.ru

---

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**№ 72** **15 апрель 2015 ел**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта хупларга һәм гавами тыңлауларга чыгарырга

2. Мәгълүмати стендта урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының әлеге карары «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында».
- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы карары проекты (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карары проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар 2015 елның 15 маенда 15.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча узачак: Бәркәтә авылы, Ленин урамы, 76 а йорт.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Уставына кергән тәкъдимнәрне, үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

Гайнанова Гөлфания Хәниф кызы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы.

Дәүләтшина Рәмзия Салихҗан кызы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

Гыймранова Гүзәл Минәхмәт кызы - Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече.

5. Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге советының эшче төркеме, халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм авыл җирлеге Советы сессиясенә карауга кертергә тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенә йөкләргә.

Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе Г.Х. Гайнанова

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советы
карарына
15 апрель, 2015, № 72

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1. 5 статьяның 1 өлешен «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен яңа редакциядә бәян итәргә»:**

«1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау;

2) җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;;

3) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү;

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

5) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

7) җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) җирлекнең архив фондларын формалаштыру;

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, шул исәптән биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен, тиешле биналарның һәм корылмаларның фасадларын һәм коймаларын тышкы кыяфәтен карап тоту буенча таләпләрне билгеләүче, аларны төзекләндерү буенча эшләр исемлеге һәм аларны башкаруның ешлыгы; биналарның (алардагы бүлмәләрнең) һәм корылмаларның якын-тирә территорияләрен төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткеч урнаштыру, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту);

10) адресация объектларына адреслар бирү, үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту».

**2. «Җирлекнең җирле үзидарә органнарының җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары» 6 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 11,12 пунктчалар белән тулыландырырга:**

«11) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү;

12) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру».

**3. 30 статьяны «Җирлек Советы депутаты статусы» яңа редакциядә бәян итәргә:**

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре аны сайланганнан соң башлана һәм яңа чакырылыш җирле үзидарәнең сайланулы органы эшли башлаганнан бирле туктатыла.

Алдагы чакырылыш авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре җирлек Советы оешкан көннән туктатыла.

2. Җирлек Советы депутаты, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм хезмәт вазыйфаларын башкару белән бергә алып бара.

3. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә һәм бурычларны үтәргә тиеш. Җирлек Советы депутаты, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек милекчеләре һәм һөнәр берлеге ширкәтләреннән тыш), әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса яисә әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашырга йөкләнмәгән булса;

2) башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка

иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

3) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

4. Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен законнар, җирлек Советы карарлары нигезендә каршылыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.

5. Җирлек Советы депутаты җирлек Советы тарафыннан расланган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә, шул исәптән түбәндәге йөкләмәләрне үтәргә тиеш:

1) шәхсән яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмаска;

2) депутат вазыйфаларын объектив башкаруда шик уятырга мөмкин булган тәртиптән тыелырга, шулай ук аның абруена яисә җирлек советы абруена зыян китерергә сәләтле низаглы ситуацияләрдән котылырга.;

3) мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү куркынычы янаганда - шәхси кызыксыну депутатлык вазыйфаларының объектив башкарылуына тәэсир итә яки йогынты ясый ала торган хәл, бу хакта җирлек советына хәбәр итә һәм әлеге мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга яки җайга салуга юнәлтелгән аның карарын үтәргә мөмкин;

4) җирлек Советында билгеләнгән халык алдында чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда, Федераль закон нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган мәгълүматларны таратмаска һәм кулланмаска;

6) физик һәм юридик затлардан депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләр алмаска (бүләкләр, акчалата бүләк, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары һәм башка бүләкләүләр).

**4. «Башкарма комитет вәкаләтләре» 49 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:**

1. Авыл җирлеге башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- җирлек бюджеты проектын, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнары һәм программалары проектларын эшли һәм Совет каравына чыгара;

- җирлек бюджетын раслауны һәм үтәүне тәэмин итә, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш программаларының һәм планнарының үтәлешен оештыра;

-аның үтәлешен контрольдә тота;

- җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш программаларының һәм планнарының үтәлеше турында отчет әзерли;

- җирле салымнар һәм җыемнар билгели, үзгәртә һәм юкка чыгара;

- җирлекнең икътисад һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына бирүне оештыра.

2) җирлек территориясендә муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә:

- җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәте белән идарә итә, муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, куллану, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән җирлекнең икътисади һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзи;

- җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр булдыруга ярдәм итә;

- муниципаль заказны формалаштыра һәм урнаштыра;

- җирлекне төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм ремонтлау, продукция җитештерү, халыкның көнкүреш һәм социаль - мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү, моның өчен каралган үз матди һәм финанс чараларын кулланып башка эшләрне башкаруга заказ бирүче булып тора;

- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны гамәлгә ашыра, җирлек чикләрендә муниципаль торак фонды булган күп фатирлы йортларга энергетика тикшерүен оештыра, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда каралган башка чаралар оештыра һәм үткәрә.

- җирлекнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программасын эшли һәм тормышка ашыра, аларга карата таләпләр Россия Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3) Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, яклау өлкәсендә

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итә;

-җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;

4) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра, базарлар, ярминкәләр оештыра;

- халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тудыра, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыра;;

- җирлекнең архив фондларын формалаштыра;

- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм тормышка ашыра;

- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыра һәм җирләү урыннарын карап тотуны тәэмин итә;

5) төзекләндерү өлкәсендә:

-җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслый, шул исәптән биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен

карап тоту буенча да, тиешле Биналарның һәм корылмаларның фасадларын һәм киртәләрен тышкы кыяфәтенә карата да таләпләр раслый;

-төзекләндерү буенча эшләр исемлеген һәм аларны башкару ешлыгын раслый;

- биналарның (алардагы бүлмәләрнең) һәм корылмаларның милекчеләренең якын-тирә территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү;

- тирә-юнь территорияләрен төзекләндерүне (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны да кертеп) оештыра;

- адресация объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына атамалар бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш);

җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирә, мондый атамаларны үзгәртә, юкка чыгара;

-дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыра;

- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыра;

6) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

7) авыл хуҗалыгын һәм эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә:

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра, авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә шартлар тудыра;

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс чараларын исәпкә алып бара һәм тиешле файдалануны тәэмин итә;

- федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра;

- Җирлекнең җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә, җирлек Советы карарлары нигезендә аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен;

- кирәк булганда, Чирмешән муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы белән җирлек бюджетын формалаштыру һәм үтәү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзи

9) башка вәкаләтләр:

- җирлек башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка яктан тәэмин итүне башкара;

-җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында гражданнарны җирлек өчен әһәмиятле булган социаль әһәмиятле эшләрне ( шул исәптән дежурлыкларны) ирекле рәвештә башкаруга җәлеп итү турында карар кабул итә һәм аларны үткәрүне оештыра.

- җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча, законнар, әлеге Устав, җирлек Советы карарлары белән җирлек Советы яисә башка җирле үзидарә органнары вәкаләтләреннән тыш, башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Башкарма комитет җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- җирлек музейлары булдыра;

- җирлектә нотариус булмаган очракта законнарда каралган нотариаль гамәлләр башкару;

- опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнаша;

- җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни мохтариятләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар тудыра;

- туризм өчен шартлар тудыру;

- муниципаль янгын сагы булдыру;

- опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнашу;

- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга ярдәм итә;

- җирлек территориясендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм тормышка ашыруда катнаша;

- кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм итә.

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук Гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтә.

- федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар хезмәт күрсәтүләренең сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру;

- торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү.

3. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә, федераль законнарда каралган булса, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашырга, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кермәгән һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән аларның компетенциясеннән төшереп калдырылмаган һәм җирле бюджетлар керемнәре исәбеннән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керемнәреннән тыш, башка мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы».

**5. «Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе» 71 статьясындагы 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:**

«- массакүләм мәгълүмат чараларында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»Интернет-ресурсын урнаштыру юлы белән.

**6. «Җирлектә бюджет процессы» 78 статьясын яңа редакциядә бәян итәргә:**

1. Җирлек бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла. Җирлек бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

2. Җирлек бюджеты проекты, җирлек советы карары, җирлек бюджетын раслау турында, аның үтәлеше турында еллык хисап, квартал саен район бюджетын үтәүнең барышы һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре саны турында мәгълүмат, аларны тотуга факттагы чыгымнарны күрсәтеп, рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

3. Җирлек советының чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының керемнәрен (чыгымнарын) үзгәртүгә китерә торган карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән салымнар һәм җыемнар турындагы норматив-хокукый актларына үзгәрешләр кертүне күздә тотучы норматив хокукый актларында Чираттагы финанс елыннан соң килгән елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча җирлек Советының күрсәтелгән норматив хокукый актларының үз көченә керүе турындагы нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш.

5. Җирлек бюджеты проекты Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый акты нигезендә өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

6. Җирлек бюджеты проекты, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның Бюджет кодексына туры китереп, кабул ителгән Бюджет кодексы нигезендә, җирлек башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган нигезләмәләре;

бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

Россия Федерациясе таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре;

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

8. Бюджет турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (профициты), шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе субъектлары законнары, Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарының муниципаль хокукый актлары (бюджет турында законнардан (карарлардан) тыш) белән билгеләнгән башка күрсәткечләр булырга тиеш.

9. Җирлек бюджеты турындагы карар белән составы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары, җирлек Советының муниципаль хокукый актлары нигезендә билгеләнә торган күрсәткечләр раслана.

10. Район бюджеты турындагы карар белән билгеләнә:

район бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеге;

район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеге;

чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемнәре) буенча йә чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемнәре) һәм (яисә) максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре (төркемнәре һәм төркемнәре) буенча, шулай ук әлеге Кодекста, законда, законда билгеләнгән очракларда бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый акты белән;

Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасы;

гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

чираттагы финанс елында һәм план чорында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан алына торган һәм (яки) башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

план чорының беренче елына район бюджеты чыгымнарының шартлы рәвештә расланган чыгымнарының гомуми күләме район бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елына район бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (максатчан билгеләнеше булган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар хисабына каралган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары;

чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге (шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп);

җирлек бюджетының Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка күрсәткечләре.

11. Җирлек бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта җирлек Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә документлар һәм материаллар тапшырыла.

12. Җирлек бюджеты турында карар проектын карау һәм аның теләүнең муниципаль хокукый актында билгеләнгән раслау тәртибе чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан бюджет турындагы карарның үз көченә керүен, шулай ук күрсәтелгән карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясы нигезендә күрсәткечләрне һәм характеристикаларны раслауны күздә тотарга тиеш.

13. Җирлек бюджеты турындагы карар 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексы яки җирлек бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса, финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Җирлек бюджеты турындагы карар, аңа кул куелганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча, билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

14. Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирлек бюджетының балансслылыгын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, муниципаль бурыч дефициты, күләме һәм структурасы, җирлекнең бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән үтәлешен тәэмин итә.

15. Җирлек бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә формалаша.

16. Җирлек бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган рәвешләрдә гамәлгә ашырыла.

Федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга җирлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

17. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советы
карарына
15 апрель 2015 ел, № 72

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен һәм гражданнарның фикер алышуларда катнашуын исәпкә алу**

**ТӘРТИБЕ**

1. Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы турында» гы карары проектына тәкъдимнәр Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 423106, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Бәркәтә авылы, Ленин урамы, 76а йорт, яисә факс буенча (84396) 2-64-66 язма рәвештә яисә кушымта итеп бирелә торган төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| №/№ п/п | Статья, өлеш, пункт, пунктча | Устав тексты | Уставка төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» гы карары стендка урнаштыру юлы белән басылганнан соң бер ай дәвамында 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр эш көннәрендә кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча ( 423106, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Бәркәтә авылы, Ленин урамы, 76 а йорт), шәхсән яки почта аша («Устав турында фикер алышу» яки «халык алдында тыңлауларга»конвертында тамгасы белән), шулай ук 2-64-66 телефоны буенча (84396) 2-64-66 факс буенча кабул ителә. Гражданнар тәкъдимнәре Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советы хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен авыл җирлеге Советының эш комиссиясенә тапшырыла.

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге  Советы
карарына
15 апрель 2015 ел, № 72

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба - гавами тыңлаулар)  Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.
2. Ачык тыңлауларда Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә  авыл җирлегендә яшәүчеләр (алга таба - авыл халкы) үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән чыгыш ясыйлар, алар Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге Советына халык алдында тыңлаулар үткәрү датасына 7 көннән дә соңга калмыйча язмача гаризалар бирәләр.
3. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гариза бирмичә генә чыгыш ясау хокукы белән авыл җирлеге Советы депутатлары, авыл җирлеге башлыгы, аның урынбасары, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, район прокуроры, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Территориаль дәүләт хакимияте органнары һәм идарәсенең Чирмешән районындагы вәкаләтле вәкилләре.
4. Ачык тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.
5. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.
6. Халык алдында тыңлауларда авыл җирлеге башлыгы яисә аның кушуы буенча районның җирле үзидарә органының башка вазыйфаи заты рәислек итә.
7. Халык алдында тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
8. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен, рәис тәкъдиме буенча гавами тыңлаулар секретариаты рәислек итүче һәм секретариатның ике әгъзасы составында сайлана.
9. Төп доклад белән авыл җирлеге Советы депутаты, Авыл җирлеге Советының җирле үзидарә, Совет, хокук тәртибе, экология һәм халык

куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе карары белән вәкаләтле вәкил чыгыш ясый.

10. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

11. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 2 минуттан да артык түгел.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

13. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

17. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә кушыла.

18.Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм авыл җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

19. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә Авыл җирлеге Советының җирле үзидарә, Совет, хокук тәртибе, экология һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе тарафыннан әзерләнә.

20. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә стендта урнаштыру юлы белән бастырып чыгарылырга тиеш.

21. Ачык тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү авыл җирлеге Советы аппараты һәм авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан җирле бюджет хисабына башкарыла.